**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**

**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 55-11 “26 " октябрь 2021 ел

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен муниципаль район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, 2015 елның 29 августындагы 175-48 нче номерлы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр җирле үзидарә органнары һәм Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәр Советы
карар **итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен хәл итүне тәкъдим итәргә:

- күпфатирлы йортта идарә итү ысулын һәм торак урыннар милекчесен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән, социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча һәм торак урыннар милекчеләре өчен торак урыннарны карап тоткан өчен тарифларны раслауны.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатында «2022 елга һәм план 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджет турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин